**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА СТАРОЧЕЛНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**423004, с. Старые Челны, ул. Гагарина, дом 6, телефон:8(843)45-3-55-73**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**423004, Иске Чаллы авылы, Ленин ур., 6 йорт, телефон:8(843)45-3-55-73**

ОГРН 1021605352449,ОКПО 04312558, ОКАТО 92246876000,
ИНН/ КПП 1632001610/163201001,ОКТМО 92646476

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«30» октябрь 2019 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылында Гагарин, Молодежная, Центральная урамнарында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын Ленин урамы, 3А адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында 2019 елның 19 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. 2019 елның 20 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Ленин урамы буенча 3А адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылында Луговая һәм Заречная урамында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 21 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Ленин урамы буенча 3А адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылында, Полевая урамында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2019 елның 22 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Ленин урамы, 3А адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылында Чапаев, Заречная һәм Мәктәп тыкрыгында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын оештыру һәм уздыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлыгы булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1). Түбән Чаллы авылын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү;

2). Авыл хуҗалыгы техникасына тагылмалы җиһазлар сатып алу:

« ӘЙЕ» «ЮК» »

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Иске Чаллы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

9. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Глава
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров